Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданка С.Ә. Сабирова шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 2 пунктындагы беренче һәм икенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2021 елның 13 апреле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 2 пунктындагы беренче һәм икенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка С.Ә. Сабирова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Э.М. Мостафина мәгълүматын, яклар — гражданка С.Ә. Сабирова, шикаять белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары А.В. Егоров аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка С.Ә. Сабирова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 2 пунктындагы беренче һәм икенче абзацлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Тәртипнең 2 пунктындагы беренче абзацында билгеләнгәнчә, транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет (алга таба шулай ук — юл йөрү билеты) һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләре өчен (бу Тәртипнең 3 пунктындагы «т» пунктчасында күрсәтелгән гражданнардан тыш) шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында һәм шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә йөрү хокукы бирә. Тәртипнең 2 пунктындагы икенче абзацы бу Тәртипнең 3 пунктындагы «т» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өчен юл йөрү билеты муниципаль берәмлек чикләрендә шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында һәм шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә

йөрү хокукы бирүен күздә тота. Тәртипнең 3 пунктындагы «т» пунктчасы гражданнарның түбәндәге категорияләрен үз эченә ала: пенсионерлар, 60 һәм 55 яше тулган (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) гражданнар, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 2018 елның 31 декабренә 60 һәм 55 яше тулмаган (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), Тәртипнең 3 пунктындагы «а»—«с» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар категориясенә керми торган гражданнар (алга таба — пенсионерлар).

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — пенсионер һәм шәһәр яны элемтәсенең җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүче (Казан шәһәре — Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы) муниципальара маршрутындагы «Казан — Арышхазда» 112 маршруты автобус хезмәтеннән файдалана. Әлеге маршрутта йөрүче пассажирларның төп контингентын пенсионерлар — бакча ширкәтләре әгъзалары тәшкил итә.

Гражданка С.Ә. Сабирова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мөрәҗәгать иткән, аннан алган җавапта пенсионерлар өчен юл йөрү билеты муниципаль берәмлек чикләрендә шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында ташламалы йөрү хокукы бирә дип күрсәтелгән.

Ул, Тәртипнең 2 пунктындагы икенче абзацында «муниципаль берәмлек» термины астында муниципаль берәмлекләрнең ике төре генә: муниципаль районнар һәм шәһәр округлары күз алдында тотыла, дип саный. Бу очракта әлеге норма шәһәр яны элемтәсендә, мәсәлән, бер муниципаль район чикләрендәге шәһәр һәм авыл арасында кулланылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон, «шәһәр яны элемтәсе» төшенчәсенә, бер муниципаль район

чикләрендәге шәһәр яны элемтәсенә һәм берничә муниципаль район чикләрендәге шәһәр яны элемтәсенә бүлмичә генә, төгәл билгеләмә бирә, дип билгеләп үтә. Аның фикеренчә, дәгъва белдерелә торган нормаларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тиешле хокукый җайга салу максатларында фактта шәһәр яны элемтәсенең төрләрен билгеләгән. Шуңа бәйле рәвештә гражданка С.Ә. Сабирова, карала торган социаль ярдәм чарасына хокук барлыкка килүгә йогынты ясый торган бу бүленеш тигезлекнең һәм гаделлекнең конституциячел принцибын боза, чөнки шәһәр яны элемтәсенең күрсәтелгән төрләрендә объектив аермалар юк — һәрхәлдә, пассажирлар йөртү һәм багаж ташу ераклыгы илле километрдан артмаска тиеш һәм ул торак пунктлар арасында гамәлгә ашырылырга тиеш, дип саный.

Мөрәҗәгать итүче, пенсионерлар — гражданнарның аеруча мохтаж һәм социаль якланмаган категориясенең берсе, әмма шикаять белдерелә торган нормаларда алар, аерым алганда, Татарстан Республикасының дәүләт социаль хезмәт күрсәтү системасы хезмәткәрләренә карата дискриминация хәлендә булган, чөнки Тәртипнең 3 пунктында пенсионерлар өчен генә шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында йөрү өчен бердәм айлык социаль билет буенча йөрү хокукы бер муниципаль берәмлек эчендә чикләнгән, дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка С.Ә. Сабирова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 2 пунктындагы беренче һәм икенче абзацларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 28 (беренче өлеш), 32, 38 (беренче өлеш) һәм 39 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау —

Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; закон һәм суд каршында һәркем тигез; шәхеснең абруе дәүләт тарафыннан саклана; аны төшерү өчен бернәрсә дә нигез була алмый; гаилә, ана булу, ата булу, балачак һәм картлык дәүләт яклавында; Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә ирекле күчеп йөрү, яшәү һәм тору урынын сайлау хокукы гарантияләнә; бу хокукны чикләү федераль закон белән билгеләнергә мөмкин.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 2 пунктындагы беренче һәм икенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләре, анда пенсионерлар өчен шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында йөрү өчен бердәм айлык социаль билет буенча йөрү хокукы бер муниципаль берәмлек эчендә чикләнгән дәрәҗәдә әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау өлкәсенә карый, ул Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты). Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясындагы 2 һәм 5 өлешләр).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясындагы 2 пунктының 12 пунктчасы нигезләмәләренә таянып, шәһәр яны һәм муниципальара даими йөртүләрдә автомобиль транспорты ярдәмендә халыкка транспорт хезмәтен оештыру мәсьәләләрен хәл итү Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләренә керә, аларны әлеге органнар Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары (федераль бюджеттан субвенцияләрдән тыш) исәбеннән мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашыра.

Әлеге Федераль законның 26.3-1 статьясындагы өченче өлешендә каралганча, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категориясе өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары

белән билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел.

Россия Федерациясе субъектларына бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, республика закон чыгаручысы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль хезмәт күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасында адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган гражданнар категориясен ачыклаган, шулай ук пенсионерларга социаль ярдәм күрсәтү чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында һәм муниципаль берәмлекләр бюджетларында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырылуын билгеләгән (2 статьяның 2 пункты).

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны кабул итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 103 статьясына нигезләнгән вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, аның буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы территориясендә федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри булган карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 статьясындагы беренче өлеше белән үзара бәйләнештә 13 статьясы нигезендә Татарстан Республикасында, сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм иркле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт буларак, һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән, туендыручысын югалткан очракта,

балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә. Монда Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 статьясындагы беренче өлешенең мәгънәсе буенча социаль тәэминат Татарстан Республикасы законында билгеләнгән очракларда һәм күләмнәрдә социаль ярдәм чараларын бирүне үз эченә ала.

Китерелгән конституциячел нигезләмәләрдән закон чыгаручының яше, сәламәтлеге һәм башка үзләреннән бәйле булмаган сәбәпләр аркасында эшли алмаучылар өчен үз хокукларын гамәлгә ашыруда тиешле шартлар булдыруны һәм гражданнарның аеруча якланмаган категориясенә ярдәм итүне тәэмин итәрлек социаль яклау системасын урнаштыру бурычы килеп чыга. Монда, Татарстан Республикасы Конституция суды берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, пенсионерларның матди тәэмин ителеш дәрәҗәсе алына торган пенсия суммасыннан гына түгел, ә социаль хезмәт күрсәтүләргә һәм төрле ташламалар булуга да бәйле (2014 елның 3 июлендәге 59-П номерлы карар, 2002 елның 11 июнендәге 4-О номерлы билгеләмә).

Бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, гражданнарның башка категориясе белән беррәттән, пенсионерлар өчен әлеге максатларда бердәм социаль юл йөрү билеты кертеп, шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә һәм шәһәр яны автомобиль транспортында ташламалы йөрү хокукын да күздә тоткан. Әлеге социаль ярдәм чарасы максатчан характерда, аерым категорияләрдәге гражданнарның матди иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән өстәмә социаль ярдәм чарасын билгеләү — Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы. Бу ярдәм күрсәтү нигезләре һәм шартлары социаль-икътисадый үсешнең әлеге этабындагы финанс һәм башка матди мөмкинлекләрне исәпкә алып, республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә дигәнне аңлата.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе нигезендә гаделлек, тигезлек һәм ярашканлык конституциячел

принципларыннан закон чыгаручыга юнәлтелгән бер үк категориягә караган затларның хокукый хәлендә объектив һәм акылга ярашлы аклануга ия булмаган аерымлыклар кертүне тыю (бер үк яки охшаш хәлләрдә булган затлар белән төрлечә эш итүне тыю) килеп чыга. Хокукый җайга салуның теге яисә бу өлкәсендә гражданнарның хокукларындагы аермаларга китерә торган теләсә нинди дифференциация Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 17 (3 өлеш), 19 (1 һәм 2 өлешләр) һәм 55 (3 өлеш) статьялары таләпләренә җавап бирергә тиеш, әгәр алар объектив акланган, нигезләнгән һәм конституциячел әһәмиятле максатларга туры килсә генә рөхсәт ителә, ә әлеге максатларга ирешү өчен кулланыла торган хокукый чаралар шуларга тиң (2001 елның 24 маендагы 8-П номерлы, 2007 елның 5 апрелендәге 5-П номерлы, 2010 елның 3 февралендәге 3-П номерлы, 2012 елның 27 февралендәге 3-П номерлы, 2019 елның 22 мартындагы 15-П номерлы һәм башка карарлар).

3.1. Карала торган Тәртип Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет буенча йөрү рәвешендә социаль ярдәм чарасы бирелә торган гражданнар категориясен билгели, шулай ук күрсәтелгән гражданнар тарафыннан әлеге социаль ярдәм чарасын гамәлгә ашыруның оештыру-процедура механизмын ачыклый.

Шул ук вакытта, әгәр шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә йөргәндә Тәртиптә күрсәтелгән барлык категория гражданнар өчен аталган социаль ярдәм чарасы бертөрле күләмдә билгеләнсә, шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында йөргәндә транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет буенча йөрү хокукы бер муниципаль берәмлек эчендә чикләнгән пенсионерлар арасында һәм Тәртипнең 3 пунктындагы «а»—«с» пунктчаларында санап үтелгән шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында бер муниципаль берәмлек чикләре белән чикләнмәгән бердәм айлык социаль билет буенча йөрү хокукы булган башка категориядәге гражданнарга күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары күләмендә аерымлыклар бар. Аларга түбәндәгеләр керә: Бөек Ватан сугышы

инвалидлары; Бөек Ватан сугышында катнашучылар; хәрби хәрәкәтләр ветераннары; 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 3 сентябренә кадәрге чорда кимендә алты ай хәрәкәттәге армия составына кермәгән хәрби частьларда, учреждениеләрдә, хәрби уку йортларында хәрби хезмәт үткән хәрби хезмәткәрләр; шулай ук әлеге чордагы хезмәте өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән хәрби хезмәткәрләр; «Камалыштагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затлар; Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге фронтларның тыл чикләрендә, хәрәкәттәге флотларның операция зоналары чикләрендә, тимер юллар һәм автомобиль юлларының фронт буендагы участокларында һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, җирле һава һөҗүменә каршы оборонада, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм башка хәрби объектлар төзелешендә эшләгән затлар; Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында иректән мәхрүм ителгән транспорт флоты суднолары экипажлары әгъзалары; һәлак булган (үлгән) Бөек Ватан сугышы инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзалары, җирле һава һөҗүменә каршы оборонаның объект һәм һәлакәт командалары саклану төркемнәренең шәхси составы арасыннан Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларның гаилә әгъзалары, шулай ук Ленинград шәһәре госпитальләре һәм хастаханәләренең һәлак булган хезмәткәрләренең гаилә әгъзалары; «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килгән хезмәт ветераннары, бүтән нигезләр буенча пенсия алучы яки 60 һәм 55 яше тулгач (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) эшләгән (хезмәт иткән) өчен гомерлек түләү алучы хезмәт ветераннары, 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр чорда, СССРның вакытлыча басып алынган территорияләрендә эшләгән чорны

кертмичә, тылда кимендә алты ай эшләгән затлар; Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән затлар; реабилитацияләнгән затлар һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затлар; Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган затлар, аеруча хәтәр яный торган төркемгә керүче гражданнар; I группа инвалидларын (хезмәт эшчәнлегенә мөмкинлеге III дәрәҗәдә чикләнгән) яки инвалид балаларны (һәр I төркем инвалидка (хезмәт эшчәнлегенә мөмкинлеге III дәрәҗәдә чикләнгән) яки инвалид балага бер озатып йөрүчедән артык түгел) озатып йөрүче затлар; «СССРның мактаулы доноры», «Россиянең мактаулы доноры» билгеләре белән бүләкләнгән затлар; инвалидлар; Татарстан Республикасының дәүләт социаль хезмәт күрсәтү системасы хезмәткәрләре; икенче бөтендөнья сугышы дәверендә фашистлар һәм аларның союздашлары тарафыннан корылган концлагерьларның, гетто, башка төрле ирексезләп тотылу урыннарының балигъ булмаган элеккеге тоткыннары; «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килгән, «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, картлык буенча яки тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажлары булган затлар, шулай ук бүтән нигезләр буенча пенсия алучы яки 60 һәм 55 яше тулгач (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) эшләгән (хезмәт иткән) өчен гомерлек түләү алучы «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасының

дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затлар.

Тәртипнең 3 пунктындагы «а»—«с» («п» пунктыннан тыш) пунктчаларын анализлау түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкинлек бирә: Татарстан Республикасы, анда санап үтелгән категорияләргә кертелгән гражданнарның казанышларын да, шулай ук аларга китерелгән мөлкәти зыянны һәм алар кичергән әхлакый газапларны танып, аларны социаль яклауны гамәлгә ашыру буенча үзенә аерым гавами-хокукый йөкләмәләр кабул иткән һәм пенсионерлар белән чагыштырганда социаль ярдәм чараларын күбрәк күләмдә бирә торган һәм үз максаты белән мондый гражданнарга матди югалтуларны тулыландыру, шулай ук дәүләт исеменнән аларга җәмгыять һәм дәүләт алдындагы хезмәтләре өчен рәхмәт белдерү булган шундый хокукый җайга салуны күздә тоткан.

«Татарстан Республикасының дәүләт социаль хезмәт күрсәтү системасы хезмәткәрләре» категориясенә карата (Тәртипнең 3 пунктындагы «п» пунктчасы) шуны билгеләп үтәргә кирәк: «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә социаль ярдәм күрсәтү һәм кызыксындыру чараларын билгеләү кертелгән (4 статьяның 14 пункты). Әлеге категория гражданнарның бердәм социаль юл йөрү билеты буенча барлык маршрут төрләрендә дә түләүсез йөрүен тәэмин итү аларның даими йөрү белән бәйле хезмәт вазыйфаларын башкару кирәклегеннән килеп чыга.

Шулай итеп, пенсионерлар һәм башка категория гражданнар өчен төрле социаль ярдәм чараларын билгеләү объектив сәбәпләргә бәйле, дәүләт социаль ярдәмен күрсәтүнең адреслылык принцибына җавап бирә һәм гражданнарның, шул исәптән гражданка С.Ә. Сабированың да, конституциячел хокукларын боза торган булырак карала алмый.

Мондый алым 1966 елның 16 декабрендәге Граждан һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактны гамәлгә ашыруны тикшереп торучы Кеше хокуклары буенча комитетның хокук куллану практикасына туры килә, аның нигезендә закон каршында тигез булу хокукы һәм бернинди дискриминациясез закон белән бертигез яклану хокукы мөрәҗәгатьтәге теләсә кайсы аерымлык дискриминацияле дигәнне аңлатмый, шуңа күрә резонлы һәм объектив критерийларга нигезләнгән дифференциация Пактның 26 статьясы мәгънәсе буенча тыелган дискриминация белән бер үк түгел (Комитетның 1987 елның 9 апрелендәге 182/1984 номерлы карарының 13 пункты).

3.2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы нигезендә муниципаль берәмлек — шәһәр яисә авыл җирлеге, муниципаль район, шәһәр округы, шәһәр эче бүленеше белән шәһәр округы, шәһәр эче районы яисә федераль әһәмияттәге шәһәрнең шәһәр эче территориясе. Күрсәтелгән хокукый норма нигезендә кайбер муниципаль берәмлекләр мөстәкыйль муниципаль берәмлекләрдән тора. Шулай итеп, муниципаль район — бер гомуми территориягә берләштерелгән, чикләрендә җирле үзидарә җирлекара характердагы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында халык тарафыннан турыдан-туры һәм (яисә) җирле үзидарәнең сайланулы һәм башка органнары аша гамәлгә ашырыла торган һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән тапшырыла торган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра ала торган берничә җирлек яисә җирлекләр һәм җирлекара территорияләр; шәһәр эче бүленеше белән шәһәр округы — Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә шәһәр эче муниципаль берәмлекләре буларак шәһәр эче районнары төзелгән шәһәр округы. Шулай итеп, муниципаль район һәм шәһәр эче бүленеше белән шәһәр округы кебек муниципаль берәмлекләр мөстәкыйль муниципаль берәмлекләрне үз эченә ала.

Югарыда аталган Федераль законның 15 (1 өлешнең 6 пункты) һәм 16 (1 өлешнең 7 пункты) статьялары нигезләмәләре буенча күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә шул исәптән халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтүне оештыру да керә.

Россия Федерациясе транспорт системасының бер өлеше булып торган автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты хезмәтләре күрсәткәндә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» Федераль законы белән җайга салына. Күрсәтелгән Федераль законның 4 статьясындагы 3 өлеше белән шәһәр яны элемтәсендә, әлеге торак пунктларның чикләре арасында илле километрга кадәр ераклыкны кертеп, пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру каралган. Әлеге Федераль законның 5 статьясы нигезендә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу төрләре түбәндәгеләр: даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу; заказлар буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу; җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу. Үз чиратында «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон белән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу җайга салына торган тарифлар буенча һәм җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга бүленә (3 статьяның 1 өлешендәге 16 пункты).

Эшне тыңлау барышында дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган як вәкиле Татарстан Республикасының бер муниципаль районы чикләрендә һәм шәһәр округы чикләрендә транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет күрсәткән пенсионерлар даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен түләүдән, шул исәптән җайга

салынмый торган тариф буенча да, азат ителүен аңлатты.

Шулай итеп, китерелгән хокукый җайга салу һәм килеп туган хокук куллану практикасы һәр муниципаль берәмлектә, шул исәптән шәһәр эчендәге бүленеше булган шәһәр округында һәм муниципаль районда, шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында һәм шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә йөргәндә, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу төренә карамастан, пенсионерлар транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет күрсәткән очракта, йөргән өчен түләүдән азат ителәләр, дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Шулай, бер муниципаль районда яки шәһәр округында башланган, ә башка муниципаль районда яки шәһәр округында тәмамлана торган маршрут буенча җайга салынмый торган тариф буенча шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында йөргәндә, пассажирлар йөртүче тарафыннан билгеләнгән тариф бер муниципаль берәмлек чикләрендә пассажирның йөрү бәясенә киметелергә тиеш. Әлеге социаль ярдәм чарасы, транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет алу урынына бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гамәлдә була.

3.3. Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясендә, аның 1 (1 өлеш), 4 (2 өлеш), 15 (1 һәм 2 өлешләр) һәм 19 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында беркетелгәннәрдән килеп чыга торган хокукый норманың билгелелеге, ачыклыгы һәм ике төрле аңлашылмаучанлыгы гомумхокукый критериен, хокукый дәүләт, закон өстенлеге һәм юридик тигезлек принципларын үтәмичә, аны бертөсле аңлау һәм, димәк, куллану мөмкин түгел; хокукый җайга салуның бер мәгънәле булмавы, ачык булмавы һәм каршылыклылыгы аның эчтәлеген тәңгәл аңлатуга каршы килә, хокук куллану процессында чикләнмәгән карау мөмкинлеген бирә, башбаштаклыкка китерә һәм шуның белән конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен какшата (2011 елның 20 декабрендәге 29-П номерлы, 2015 елның 2 июнендәге 12-П номерлы, 2017 елның 19 июлендәге 22-П номерлы, 2018

елның 16 мартындагы 11-П номерлы һ.б. карарлар).

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә торган гомуми файдаланудагы шәһәр автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хезмәте күрсәтүгә тарифлар, 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташуга җайга салынулы тарифларны билгеләү тәртибеннән күренгәнчә, дифференциацияләнгән булырга мөмкин; дифференциацияләнгән тарифлар юл йөрү өчен түләү ысулларына, шулай ук пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәтләр күрсәтү шартларына бәйле рәвештә билгеләнергә мөмкин (17, 18 пунктлар). Мисал өчен, Казан шәһәр округында тарифлар транспортта йөрү өчен түләү (акчалата яки акчасыз исәп-хисап) ысулыннан чыгып һәм йөргән өчен транспорт картасы белән түләгәндә йөрү санына бәйле рәвештә дифференцияләнә (Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 20 декабрендәге 7-13/т номерлы карары); Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегендә һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегендә бер тапкыр йөрү тарифы 100 тапкыр һәм аннан да күбрәк йөрү өчен озак файдаланудагы билет белән түләгәндә һәм бер тапкыр бару өчен билет сатып алганда дифференцияләнә (Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 14 октябрендәге 108-4/т-2020 номерлы һәм 2020 елның 14 октябрендәге 110-6/т-2020 номерлы карарлары).

Карала торган Тәртипнең эчтәлегеннән җайга салынмый торган тариф буенча муниципаль берәмлекләр арасында шәһәр яны элемтәсе маршрутында йөргән өчен йөрү бәясен билгеләгәндә пенсионерларга тарифларның кайсын кулланырга кирәк булуы аңлашылмый. Мондый

хокукый җайга салу гражданнарның әлеге категориясе өчен шундый маршрутларда йөргән вакытта йөрү бәясен ирекле билгеләү мөмкинлеген калдыра, бу хокукый норманың ачыклыгы һәм бер мәгънәдә булуы гомумхокукый критерийларына туры килми һәм шуның белән аны бертөрле аңлатуга һәм куллануга ярдәм итми. Шуннан чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына гамәлдәге хокукый җайга салуга тиешле төгәллекләр кертергә кирәк.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Конституция суды бер муниципаль берәмлек чикләрендә шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында түләүсез йөрү мөмкинлеген күздә тоткан пенсионерлар өчен транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет рәвешендә бирелә торган социаль ярдәм чарасы, хәзерге вакытта булган финанс мөмкинлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы тарафыннан билгеләнгән, гражданнарның күрсәтелгән категориясе статусы белән туры килә, акылга ярашлылык, тигезлек һәм гаделлек принципларына җавап бирә, шуңа күрә гражданнарның конституциячел хокукларын бозучы буларак карала алмый, дигән нәтиҗәгә килә. Димәк, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 2 пунктындагы беренче һәм икенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләре үзләренең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча Татарстан Республикасының бер муниципаль берәмлеге, шул исәптән муниципаль район чикләрендә, пенсионерлар шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында һәм шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә йөргәндә, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу төренә карамастан, пенсионерларның, транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет күрсәткәндә, йөргән өчен түләүдән азат ителүен күздә тота һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73, 84 статьяларына һәм 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 2 пунктындагы беренче һәм икенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга, чөнки алар үзләренең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча Татарстан Республикасының бер муниципаль берәмлеге, шул исәптән муниципаль район чикләрендә, шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында һәм шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә йөргәндә, даими рәвештә пассажирлар йөртү төренә карамастан, пенсионерлар транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет күрсәткәндә, йөргән өчен түләүдән азат ителүен күз алдында тоталар.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына хокукый җайга салуга пенсионерлар өчен муниципаль берәмлекләр арасында шәһәр яны элемтәсе маршрутында йөрү өчен җайга салынмый торган тариф буенча түләүне исәпләү механизмын билгеләүгә юнәлтелгән үзгәрешләр кертергә кирәк.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан»

газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 97-П**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ * КОНСТИТУЦИОННЫЙ СУД РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ИНН 1655039191 ОГРН 1021602845241